**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 19 августындагы 2889 номерлы карары**

**«Алтын мөнбәр» XXII Казан халыкара кинофестивален әзерләү һәм уздыру чорында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү турында**

«Алтын мөнбәр» XXII Казан халыкара кинофестивален әзерләү һәм уздыру чорында куркынычсызлыкны тәэмин итү максатыннан, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 маендагы 372 номерлы «Төбәк яки муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юллары буенча транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне яисә вакытлыча туктатуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында»гы карары нигезендә:

1. **Карар бирәм**:

1.1. ихтыяҗ булган очракта, 2026 елның 4 сентябрендә 16.00 сәгатьтән 19.00 сәгатькә кадәр һәм 2026 елның 8 сентябрендә Һ.Такташ урамы буенча, Н.Назарбаев урамыннан Т.Миңнуллин урамына кадәрге участокта (ике юнәлештә), «Спорт һәм социаль проектлар дирекциясе» коммерциягә нигезләнмәгән автоном оешмасы тарафыннан билгеләнгән форма буенча махсус рөхсәтнамә белән җиһазландырылган транспорт чараларыннан кала, транспорт чаралары хәрәкәтен чикләүне кертергә;

1.2. юл хәрәкәтен оештыруның техник чараларын һәм таранга каршы техниканы урнаштыру өчен җаваплы итеп Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгын (алга таба – Оештыручы) билгеләргә;

1.3. Казан шәһәре Башкарма комитетының Транспорт комитетына (А.В.Сидоров):

1.3.1. вакытлыча юл билгеләрен урнаштыруда һәм гамәлдәге юл билгеләрен каплауда Оештыручыга ярдәм күрсәтергә;

1.3.2. транспорт чараларын куеп торуны һәм аларның хәрәкәтен вакытлыча чикләү турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл

хуҗалыгы министрлыгының Интернет челтәрендә Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы рәсми порталы» дәүләт мәгълүмат системасы составына керә торган рәсми сайтында урнаштырырга;

1.3.3. кыска вакытлы аренда хезмәте күрсәтә торган электр самокатлары (WHOOSH һәм MTC.URENT) һәм велосипедлар («Яшел шәһәр») операторлары белән берлектә әлеге карарда күрсәтелгән участокларда шәхси мобильлек чараларын куеп торуны һәм аларның хәрәкәтен тыю эшен оештырырга;

1.4. Казан шәһәре Башкарма комитетының Тышкы төзекләндерү комитетына (А.М.Шайнуров) Казан шәһәре Башкарма комитетының Вахитов һәм Идел буе районнары администрациясе (А.И.Салихов) белән берлектә хәрәкәтне вакытлыча чикләү чорында таранга каршы техника һәм (яки) таранга каршы блоклар урнаштыруда ярдәм күрсәтергә;

1.5. әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

2. **Тәкъдим итәм**:

2.1. Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсенә (Р.Д.Габитов) әлеге карар нигезендә Казан шәһәре урам-юл челтәренең югарыда күрсәтелгән участогында юл хәрәкәте иминлеген саклауны һәм оештыру-көйләү гамәлләрен башкаруны контрольдә тотуны тәэмин итәргә;

2.2. Казан шәһәре Думасы аппаратының Мәгълүмат-аналитика идарәсенә (В.А.Казанцев) урам-юл челтәренең күрсәтелгән участогында транспорт чаралары хәрәкәтен һәм аларны куеп торуны вакытлыча чикләүне кертү турында массакүләм мәгълүмат чаралары аша хәбәр итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка **йөклим**.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**